КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 615

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 53 нче; 2020 ел, 21 ноябрь, 1043 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә, 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче яшь гаилә исәпкә куела. Яшь гаилә дигәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә никахлашкан, шул исәптән бала (балалар) тәрбияләүче затлар, яисә баланың (балаларның) бердәнбер атасы йә анасы (уллыкка алучы) булган 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) зат аңлашыла.».

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин